

Мордовия хакимияте калдыкларны аерым жыюны жайга салырга һәм ка-ты конкүреш калдыкларын жыю һәм эшкәртүнен комплекслы системасын булдырырга ниятли. Бу хакта республика Башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Артем Здуновнын матбугат хезмәте хәбәр итте.

Республика Башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы ассызыклаганча: «Мордовия является участником федерального проекта «Комплексная система обращения с отходами» национального проекта «Экология». Строительство комплексного объекта обработки ТКО в Саранске позволит значительно увеличить уровень утилизации в регионе». Мәсьәләләрне жентекләп ойрәнү очен Артем Здунов эшче торкем тозергә кушкан. Шулай ук калдыкларны аерым жыюны оештыру буенча алдагы эш турында да сүз барган бу жыелышта. Халыкны каты конкүреш калдыкларынын аерым жыелмасы белән тәэмин итү рес-публика халкынын 43,6%ын тәшкил итә. Аерым жыелган калдыклар күрше тобәкләр - Пензага, Түбән Новгородка, Калуга һәм Мәскәү олкәләренә икенчел эшкәртүгә жибәрелә. Россия Гринписы мәгълүматларына караганда, 2017 елда Саранск каты конкүреш калдыкларын аерым жыю инфраструктурасынын үтемлелеге буенча илдә беренче урынга чыккан. 2019 елда 1747 тонна икенчел чимал, шул исәптән 1647 тонна макулатура, 100 тонна пластик аерым жыелган. Әмма бу юнәлештә әле зур эш башкарасы бар, шул исәптән мәгълүмати-пропаганда эшләре дә. «Белгечләр чүп-чарны сортларга аеру заводын 1,5 ел эчендә тозергә момкин, ә жәмгыятьтә калдыклар белән эш итү культурасын булдыру очен 15 ел вакыт кирәк булырга момкин, диләр», - диде Артем Здунов.

Республиканын ботен территориясенә калдыкларны аерым жыю буенча Саранск шәһәр округынын унышлы тәжрибәсен тарату моһим бурыч булып кала бирә, дип ассызыкланды ул. Шулай ук Мордовия районнарында, шул исәптән ерак торак пунктларда яшәүчеләр очен каты конкүреш калдыкларын чыгару буенча хезмәт күрсәтү момкинлеге мәсьәләсе дә каралды.

Эшләргә тиешле тагын бер тәкъдим - Саранск терри-ториясендә пластик шешә-ләр һәм алюминий банкалар кабул итүнен роботлаштырылган пунктларын урнаштыру. Бу икенчел чимал жыюнын контактсыз ысулы ботен доньяда кин таралган.

Безнен авылларыбызда каты калдыкларны жыю ничегрәк бара дигән сорау буенча күп тапкыр кызыксынып карарга туры килде. Мордовиябез авылларында каты конкүреш калдыкларын жыю үзәкләштерелгән һәм куелган бакларнын тирә-ягын да чистартып алып китәләр. Бүгенгә пластик шешә, картон һәм башка конкүреш калдыкларны бергә жыеп баралар алар. Әле генә Ромоданово районы Алтар авылы «Село Алтары. Мордовия.» дигән социаль челтәрендә менә шундый рәсемгә тап булдым. Гомуммән

алганда, татар кешесе борынгыдан чисталыгы-пахтәлеге белән билгеле. Менә йорәге әрнегән һәм халкы очен янып йоргән Алтар кешесе рәсем астында шундый комментарийлар да калдырган: «Чын-чынлап беркая сыймый торган эш бу, бvтән торле әйтергә тел дә әйләнми. Тукталышка каршы юл читендә vзләренен мусорларын ташлап калдырганнар».
Ромоданово районы Алтар авылы администрациясе житәкчесе Монир Хафиз улы Кузяев белән авылларындагы бу темага кагылышлы мәсьәләләр турында сойләштек. Ул: «Yткән елнын май аенда без «Ремондис» компаниясенен филиалы хезмәткәре белән Алтар авылында 32 контейнерга урын әзерләп кую турында сойләшкән идек. Районыбыз администрациясендә тутырылган заявкабыз да бар. Барысына якынча 800 мен сум акча таләп ителә. Әлегә «Ремондис» хезмәте Алтар мәктәбе каты калдыкларын гына ташый. Элегрәк каты отходларны vзебез чvплекләргә ташый идек, ә хәзер мона хокукыбыз юк. Хәтта ике санкциясез чvплекне яптык. Бvгенгә контейнерлар урнаштыруларын котәбез».

Башка шундый очраклар да булгалый. Мәсәлән, санкциясез чvплекләр. Авыл читендә, я булмаса ике урам артында шундый куркыныч чvплекләр vсеп килә. Беренчедән, табигатькә зыян китерәбез. Икенчедән, шул чvплекләр вакыт-вакыт яна; кырылыкта янгын чыгара шул чvплекләр, я булмаса, анда янган шешәләрдән таралган зарарлы һаваны суларга туры килә кvбебезгә. Сулап кына калмыйбыз, торле-торле авыруларга сабышабыз. Шул исәптән, яман шешләргә дә...
Ә Ләмберә районы Аксен авылы администрациясе житәкчесе Айса Жәфәр улы Юсупов белән алып барган интервьюда - каты конкvреш калдыклары (ТБО) жыю турында сойләшкән идек. Ул «Ремондис» компания торкеменен филиалы хезмәте ой алларына утызлап евроконтейнерлар куйды, дигән иде. Квитанцияләре ай саен килеп тора. Бvген бу хезмәт очен тvләве бәя булып торса да, калдыкларны аерым жиһазландырылган машиналар санкцияле чvплекләргә ташыйлар. Аксен авылы урамнары, елга буйлары-овраглары чистарды, дип шатланып куйды житәкче. Димәк, vзебез дә сау булырбыз.
Бу мәсьәлә халыкнын vзеннән тора бит: чиста кеше vз оен генә чиста тотканда тvгел, ә тирә-ягын да чиста тотканда була. Әйдәгез бер-беребезне ихтирам итик, авылларыбызны чvплек базына әйләндермик - торле яклап исән-сау булыйк!

**Наилә НАСЫРОВА**